РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы.Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
23.10.2024 №23

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
«Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл
җирлеге территориясендә җир салымы турында»
26.11.2019 елгы 21нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә туры китереп һәм федераль законнарның үзгәрүенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 26.11.2019 елгы 21нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 нче пунктта 1.2.2 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен һәм аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен;»;

1.2. 1.2 нче пунктта 1.2.3 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук "гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, моңа һәркайсының

кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренең әлеге абзацында;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә .
4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов